**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

«20» ноябрь 2019 ел. № 109

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон һәм Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә Кышлау авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләренең бер өлешен Әтнә муниципаль районы муниципаль берәмлегенә тапшырырга

1) муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару буенча;

2) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча;

3) вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча хезмәттәшлекне оештыру буенча;

4) муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү буенча;

5) вазыйфаи хәлләренә яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны тормышка ашыру (сатып алу) һәм реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында Әтнә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль хезмәткәрләренең хәбәр итү тәртибенә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру буенча;

6) муниципаль берәмлектә хезмәт урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия эшчәнлеге һәм формалаштыру буенча;

7) Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә квалификация имтиханын кабул итү, классслы чиннар бирү буенча;

8) муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру буенча; Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында;

9) Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларны диспансерлаштыруны оештыру буенча;

10) Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча;

11) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Мәгълүмат Системасына мәгълүматларны кертү, урнаштырылган мәгълүматларны актуальләштерү буенча;

12) җирлек бюджеты үтәлешен контрольдә тоту буенча;

13) җирлек бюджеты проектларына экспертиза буенча;

14) җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү буенча;

15) җирлек бюджеты акчаларын, шулай ук җирле бюджет тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган башка чыганаклардан алына торган акчаларны куллануның законлылыгына, нәтиҗәлелегенә (нәтиҗәлелегенә һәм экономлылыгына) контрольне оештыру һәм тормышка ашыру буенча;

16) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук җирле бюджет һәм җирлек милкендәге мөлкәт хисабына юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләр буенча муниципаль гарантияләр һәм йөкләмәләр бирү яки йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү законлылыгын бәяләү буенча.

17) муниципаль хокукый актлар проектларына, жирлекнен чыгым йөкләмәләренә (финанс-икътисадый нигезләмәләрнең нигезлелеген дә кертеп), шулай ук муниципаль программаларга кагылышлы өлешендә финанс-икътисадый экспертиза

18) җирлектәге бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр әзерләү;

19) Әтнә муниципаль районы Советына һәм муниципаль район башлыгына үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү буенча ;

20) вәкаләтләр чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашу буенча;

21) тышкы муниципаль финанс тикшерүе өлкәсендә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, җирлекнең Уставы һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләр;

22) эчке финанс контролен гамәлгә ашыру буенча:

- бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм башка норматив хокукый актларны үтәүне тикшерү;

- муниципаль программаларны гамәлгә ашыру, шул исәптән муниципаль биремнәрнең үтәлеше турындагы хисапларның тулы һәм дөреслеге өчен;

23) җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча;

24) җирлекнең җирле үзидарә органнары исеменнән электрон аукцион нәтиҗәләре буенча төзелә торган контракт проектының квалификациясез электрон имзасы белән көчәйтелгән җирле үзидарә органнары исеменнән кул кую буенча;

25) 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы» Федераль законда каралган мәгълүмат һәм документларны бердәм мәгълүмат системасына урнаштыру буенча;

26) муниципаль милек реестрын һәм җирлекләрнең муниципаль җирләре реестрын алып бару, муниципаль милекне, җир ресурсларын исәпкә алу системасының эшләвен, җирлекнең муниципаль милке булуы һәм аннан файдалану турындагы мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү;

27) муниципаль җирлектәге мөлкәт белән идарә итү, биләү, файдалану һәм эш итү мәсьәләсе буенча .

2. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән «Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында 1 пункт нигезендә килешү төзергә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм http://atnya.tatarstan.ru.рәсми сайтына урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Шакирова Р.Ф.